Мордовия Дәvләт Жыены рәисе Владимир Чибиркин Федерация Советы сенаторы Петр Тултаев белән интеллектуаль милекне һәм мәгарифне яклау олкәсендәге законнарнын актуаль аспектлары, шул исәптән икътисадны кадрлар белән тәэмин итv, эшче һонәрләре белгечләре әзерләv мәсьәләләре тикшерелде.
Тагын бер тема - махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларнын гаилә әгъзаларына ярдәм чараларын гамәлгә ашыру. Хакимият органнары һәм ижтимагый структуралар эшенен шул ук остенлекле юнәлеше турында Владимир Чибиркин Мордовия башлыгынын олкән кинәшчесе - ЛНР Герое Денис Кудриннын тол хатыны Татьяна Алиходжина белән очрашуда сойләде.   Ул Ватанны саклаучыларга ярдәм итv белән бәйле проектлар белән шогыльләнә. Сvз СВОда катнашучыларга законнар белән ярдәм итv турында барды - Мордовиядә әлеге категория гражданнарга һәм аларнын гаилә әгъзаларына ташламалар билгеләvче законнар кабул ителде инде.
Шулай ук очрашуда СВОда катнашучыларны тыныч тормышка кайтару, һонәри белем бирv һәм янадан укыту, эшкә урнаштыру мәсьәләләре кvтәрелде. Россия Президенты һәм Мордовия Главасы билгеләгән бурычлар кысаларында vзара хезмәт-тәшлекне дәвам итv турында килешvгә ирешелде.
Мордовия Дәvләт Жыены рәисе эш графигыннан тагы бер мисал. Владамир Чибиркин атнакич Краснослободск районында халык белән сойләде: район vзәгендә һәм районнын берничә авылында яшәvчеләрнен яшәv шартларына, территорияләрен тозекләндерvгә, пенсия белән тәэмин итvгә, торак-коммуналь хужалык хезмәтләре кvрсәтvгә бәйле мәсьәләләрне хәл итvгә багышланган очрашу vткәргән.
- Гражданнар бик кvп моһим сораулар белән килделәр. Аларны барысы да игътибар белән тынладык. Берничәсе буенча карар табылган инде, икенчеләре буенча эшне Краснослободск районы һәм Краснослободск шәһәр жирлеге башлыклары белән бергә дәвам итәчәкбез», – дип билгеләп vтте Владимир Чибиркин. - Әйтик, «Конвертор» банкрот предприятиесенен элеккеге берничә хезмәткәренен морәжәгате контрольгә алынды: алар әлегә кадәр хезмәт хакы ала алмыйлар, гәрчә алар файдасына суд карары булса да.
Район халкын уку йортларын, шул исәптән 500дән артык бала белем ала торган кvп профильле лицейны ремонтлау мәсьәләсе борчый. Бу - vсеш перспективалары булган зур мәктәп. Шуна кvрә аны 2026 елга капиталь ремонт программасына кертергә тырышачакбыз, - ди Мордовия Дәvләт Жыены рәисе.
Шул ук конне Владимир Чибиркин Краснослободск районыннан СВО катнашучылары белән дә очрашты һәм очрашуда Александр Кузовчиков белән Евгений Циндяйкинга Ватанны саклау-га керткән олешләре очен Мордовия Республикасы Дәvләт Жыелышы рәисе Рәхмәт хатларын тапшырды.
«Вся республика, в том числе и депутаты Государственного Собрания, поддерживают земляков. Каждый вопрос участников СВО и их семей находится на контроле, – диде Владимир Чибиркин. – Победа будет гарантией решения стратегических задач развития России, обозначенных Президентом нашей страны. И жители Мордовии делают все

возможное, чтобы цели специальной военной операции были достигнуты».

Наилә НАСЫРОВА